СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.09.2017 с. Набережные Моркваши № 60-255

"Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр Морквашы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында" нигезләмәне раслау хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының "Яр буе Морквашы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясын гамәлгә ашыру максатларында

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1.Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне, кушымта нигезендә, расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

3. Аның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, әһәмияте һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы ____ И.Х.Гаязов